ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 24 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $20^1$ статьяга түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$. Капиталь төзелеш объекты өчен инвестицияләрне нигезләүне әзерләү Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри булып торса, Татарстан Республикасы дәүләт милкенең мондый капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карарлар шул исәптән Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән инвестицияләрне нигезләүгә һәм аның технологик һәм бәя аудиты нәтиҗәләренә, шулай ук расланган проектлау биремена таянып кабул ителә.

Инвестицияләрне нигезләүне әзерләүгә һәм аңа технологик аудит һәм бәя аудиты үткәрүгә Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты акчалары исәбеннән бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итү тәртибе һәм күрсәтелгән бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Инвестицияләрне нигезләүне әзерләүгә һәм аңа технологик аудит һәм бәя аудиты үткәрүгә Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты акчалары исәбеннән бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру турында карарлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә.»;

2) $20^{1.2}$ статьяга түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$. Капиталь төзелеш объекты өчен инвестицияләрне нигезләүне әзерләү Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри булып торса, Татарстан Республикасы дәүләт милкенең мондый капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү турында карарлар шул исәптән Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән инвестицияләрне нигезләүгә һәм аның технологик һәм бәя аудиты нәтиҗәләренә, шулай ук расланган проектлау биремәнә таянып кабул ителә.

Инвестицияләрне нигезләүне әзерләүгә һәм аңа технологик аудит һәм бәя аудиты үткәрүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан субсидияләр бирү турында карарлар кабул итү тәртибе һәм күрсәтелгән субсидияләрне бирү тәртибе, субсидияләр бирү хакындагы килешүләргә, аларны бирү срокларына һәм шартларына таләпләрне кертеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Инвестицияләрне нигезләүне әзерләүгә һәм аңа технологик аудит һәм бәя аудиты үткәрүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан субсидияләр бирү турында карарлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә.»;

3) 50 статьяның 6 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

4) $55^2$ статьяның 2 пунктында:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:

«юл хәрәкәте иминлеге турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре;»;

б) дүртенче һәм бишенче абзацларны тиешенчә бишенче һәм алтынчы абзацлар дип санарга;

5) 77 статьяның 3 пунктындагы унберенче абзацында «ысулын үзгәрткәндә» сүзләреннән соң «, шулай ук, инвестицияләрне нигезләүне әзерләү Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри булып торса, инвестицияләрне нигезләүне әзерләү һәм аңа технологик аудит һәм бәя аудиты үткәрү максатларында» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 16 октябрендәге 79-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 27 пунктының «б» пунктчасын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 10; 2014, № 11 (I өлеш); 2016, № 25 (II өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пунктыннан һәм 2 статьясыннан тыш, 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пункты һәм 2 статьясы әлеге Законның рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2018 ел, 06 октябрь
№ 62-ТРЗ